РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БОЛЬШЕШИНАРСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы, Саба районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР
28.02.2025 — №3 -п

Татарстан Республикасы Саба районы
Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә
йорт хайваннары (этләр) йөрү урыннарын
билгеләү турында

Тиешле чисталыкны һәм тәртипне саклау, хайваннарга карата гуманлы менәсәбәтне тәэмин итү максатларында "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы; «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законнар,Россия Федерациясе Гражданлык кодексы; Россия Федерациясе Төбәкләр министрлыгының «Муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү нормаларын һәм кагыйдәләрен эшләү буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2011 елның 27 гыйнварындагы 613 номерлы боерыгы нигезендә Олы Шыңар авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннары (этләр) йерү урыннарын 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Йорт хайванын йөрткәндә, күрү сәләте буенча инвалидны озата баручы эттән тыш, түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк:

2.1. автомобиль юлының машина юлы киселешендә, лифтларда һәм күп фатирлы йортларның гомуми файдаланудагы биналарында, мондый йортларның ишегалларында, балалар һәм спорт мәйданчыкларында хайванның ирекле, контрольсез хәрәкәт итү мөмкинлеген булдырмаска;

2.2. терлекләрнең тереклек эшчәнлеге продуктларын урыннарда һәм гомуми файдаланудагы территорияләрдә җыюны тәэмин итәргә;

2.3. йорт хайванын әлеге карар белән рехсәт ителгән урыннардан читтә йөртмәскә;

2.4. этләрне торак биналардан (йортлардан) һәм аерым территорияләрдән гомуми ишегалларына һәм урамга чыгарырга:

- декоратив һәм аучылык токымнары – кыска тезгендә;

- потенциаль куркыныч этләр; биеклеге 35 сантиметрдан артып киткән этләр – кыска тезгендә, борынчыкларында (еч айга кадәрге кечекләрдән тыш);
2.5. этләрне 6.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр махсус билгеләнгән мәйданчыкта йөртергә. Әгәр мәйданчык коймa белән әйләндереп алынган булса, потенциаль куркыныч этләрдән тыш, этләрне җепсез һәм борынчыксыз йөртергә рехсәт ителә;
2.6. башка вакытта этләр урамда йөргәндә аларның хуҗалары тынлыкны тәэмин итү чараларын күрергә тиеш;
3. Тыела:
3.1. йорт хайваннарын балалар һәм спорт мәйданчыкларында, мәктәпкәчә балалар учреждениеләре, мәгариф һәм сәламәтлек саклау, мәдәният һәм спорт учреждениеләре территорияләрендә, су коену урыннарында (пляжларда), кешеләрнең күплэп ял итү урыннарында һәм җирле үзидарә органнарыбилгеләгән башка территорияләрдә йөртү, шулай УК аларның азык-телек кибетләре һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре биналарында булу.
Әлеге пунктның тәэсире эт йөртүчеләргә кагылмый.
3.2. этләрнең үз-үзен йөртүе;
3.3. йорт хайваннарын, подъездларны, баскычларны, шулай ук балалар, мәктәп, спорт мәйданчыкларын, массакүләм ял итү урыннарын, җәяүлеләр юлларын һәм машина юлларын пычрату.
3.4. наркотик, алкоголь яисә башка төрле токсик исерек хәлдәге кешеләргә-эшкә сәләтсез дип танылган затларга, ә потенциаль куркыныч этләргә 14 яшьтән кечерәк булган балаларга этләр йөртү тыела.
4. Гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтенең сакланышын мәҗбүри тәэмин итү шарты белән йорт хайваннарын йөртергә.
5. Әлеге карарны " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча , Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ shinar адресы буенча бастырып чыгарырга һәм авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырырга.
6. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл
Башкарма комитетының
28.02.2025 №3-п карарына

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә
йорт хайваннары (этләр) йөрү өчен урыннар

| № п/п | Торак пункт | Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урын |
|---|---|---|
| 1 | Олы Шыңар | социаль учреждениеләр территорияләреннән тыш, бөтен территория буенча тезгендә һәм борынчык белән |
| 2 | Кече Шыңар | |
| 3 | Оет | |
| 4 | Чулпыч | |
| 5 | Тулешкә | |